**Карар**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Түбән Ложы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**08.12.2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең **Түбән Ложы** торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Бигеш авыл җирлегенең **Түбән Ложы** торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын, белем бирүнең көндезге формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
- зират өчен җиһазлар (чүп чүкеч һәм электр генераторы) сатып алу;
- торак пункт эчендәге Үзәк урам буенча юлларны ремонтлау һәм төзекләндерү.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бигеш авыл җирлеге башлыгы ____________ (имза) И.Р. Вәлиев (имза расшифровкасы)